ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ



КАМЫРША



КАМЫРША

1

Кем күрсә дә шаккатыр,
Шаккатыр, тел шартлатыр:
— Һәй, таза да соң Тимерша,
Әй, куллары, әй, мускул!
Безнең мускул мускулмыни,
Мускул түгел ул, мыскыл...

Батырга чыгар, үскәч,
Барсын да егар, үскәч!

2

Көчле булгач шулчаклы,
Гайрәт чәчсә дә хаклы:
— Чәнчә бармак белән төртсәм,
Егармын, ди, Вафаны,
Төртмичә дә аударам, ди,
Сабир кебек җәфаны!

Юкка-барга Тимерша
Көч түкмәскә тырыша.



3

Башкалар утын вата,
Ул караватта ята:
— Беләкләрем дә тимер, ди,
Исемем дә Тимер, ди;
Балта тотсам, пычкы тартсам,
Кулымда көч кимер, ди.

Иелми дә Тимерша,
Көч сакларга тырыша.

4

Иптәшләре кар көри,
Тимерша читтә йөри:
— Нигә миңа куәтемне
Мондый эшкә вакларга?
Булыр әле сабан туйда
Шаккатырган чаклар да!

Бөгелми дә Тимерша,
Көч сакларга тырыша.



5

Язга чыккач, балалар
Басуга таралалар.

Ә Тимерша беләкләрен
Бер бөгә, бер турайта,—
Кырын яткан килеш кенә
Мускулларын зурайта.

Чыгып йөрми Тимерша,
Көч җыярга тырыша.



6

Язгы чәчүләр бетте,
Сабан туйлары җитте.

Сөлге бәйли дә биленә,
Баса уртага чыгып...
Эшләп йөргән малайларның
Бөтенесен дә егып,
Батыр калыр Тимерша,
Бүләк алыр Тимерша!

7

Чү, бу ни хәл, бу ни эш?
Болай булмаска тиеш!

Төп шикелле Тимершаны
Күтәреп алды Сабир,
Туп шикелле итеп кенә
Китереп салды Сабир!

Ә Тимерша, Тимерша
Еламаска тырыша...

8

Бөтен кеше шаккатты,
Шаккатты, тел шартлатты.

Кулларын тотып карасак,
Мөмкин түгел танырга —
Эшләмәгәч, Тимершабыз
Әйләнгән ич камырга!
Бигрәк йомшак мускул бу,
Мускул түгел, мыскыл бу!

Әй Тимерша, Тимерша,
Син бит хәзер — Камырша!

10 тиен

Художнигы Т. ХАҖИӘХМӘТОВ

Издание для детей и юношества

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

ШАУКАТ ГАЛИЕВ

(Идиатуллин Шаукат Галиевич)

КАМЫРША

Стихотворение

(на татарском языке)

ИБ № 5526

Редакторы **Т. Нурмөхәммәтов.** Художество редакторы **Ф. Хасьянова.** Техник редакторы **М. Абитова.** Корректоры **И. Иксанова.** Җыярга тапшырылды 1.12.88. Басарга кул куелды 13.02.89. Форматы $60\times90^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе № 1. «Журнальная рубленая» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 1,0. Шартлы буяу-оттиск 5,0. Нәшер-хисап табагы 1,07. Тиражы 150 000 экз. Заказ А-513. Бәясе 10 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19. КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

ББК 84 (2Р-Тат)-5
Г18

Г $\frac{4803010200-074}{М132(03)-89}$ 165—89

ISBN 5—298—00272—2

© Рәсемнәр. Татарстан китап нәшрияты, 1989.